# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Баулы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Баулы муниципаль районы составына керүче "Исергәп авыл җирлеге" һәм "Кызылъяр авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

"Баулы муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 5 (I өлеш); 2009, №6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Баулы муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Баулы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- муниципаль районы чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 4(23) - 1(75) | - Ютазы муниципаль районы |
| 1(75) - 15(24) | - Бөгелмә муниципаль районы |
| 15(24) - 2(23) | - Башкортостан Республикасы һәм Оренбург өлкәсе |

"Баулы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге
составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Баулы шәһәре |
| 2 | Александровка авыл җирлеге |
| 3 | Исергәп авыл җирлеге |
| 4 | Кызылъяр авыл җирлеге |
| 5 | Кырым-Сарай авыл җирлеге |
| 6 | Яңа Зареченский авыл җирлеге |
| 7 | Покровский Урустамак авыл җирлеге |
| 8 | Поповка авыл җирлеге |
| 9 | Потапово-Томбарлы авыл җирлеге |
| 10 | Салих авыл җирлеге |
| 11 | Татар Кандызы авыл җирлеге |
| 12 | Томбарлы авыл җирлеге |
| 13 | Удмурт Ташлысы авыл җирлеге |
| 14 | Шалты авыл җирлеге"; |

2) 3 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Кызылъяр," сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта "Александровка авыл җирлеге белән Исергәп авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге" сүзләрен "Александровка, Исергәп авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге чиге Исергәп авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгыш юнәлештә сынык сызык буенча тондыру бассейннарының төньягы буйлап инеш белән кисешкән җиргә кадәр, аннары күмәк бакчаларның көнчыгыш ягы буйлап төньяк-көнбатышка таба Нефтьче-5 күмәк бакчасына кадәр уза, Нефтьче-5 күмәк бакчасының төньягы буйлап төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң Бораулау эшләре идарәсенең күмәк бакчасын әйләнеп үтә, аннары төзелеш материаллары заводы күмәк бакчасының төньягы буйлап җитештерү объектының уртасына кадәр, шуннан соң 1,6 км төньяк-көнчыгышка

таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба электр подстанциясенә кадәр, шуннан соң 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба скважинага кадәр, шуннан соң сынык сызык буенча 1,96 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 440 м төньяк-көнбатыш юнәлештә, шуннан соң 270 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км төньяк-көнбатышка таба бара, 640 м көньяк-көнбатыш юнәлештә автомобиль юлына кадәр уза, аннары 650 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба, шуннан соң Баулы елгасының төньягы буйлап көнбатышка таба 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

г) җиденче һәм сигезенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 4 нче кушымтада:

а) бишенче абзацта "Александровка, Кызылъяр авыл җирлекләре һәм Исергәп авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге" сүзләрен "Александровка, Исергәп һәм Кызылъяр авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта "Исергәп авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге" сүзләрен "Исергәп авыл җирлеге" сүзләренә алмаштырырга һәм "Александровка авыл җирлеге, Исергәп авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге" сүзләрен "Александровка, Исергәп авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

4) 5 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Исергәп авыл җирлеге чиге Кызылъяр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Исергәп, Кызылъяр авыл җирлекләре һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Исергәп авыл җирлеге Яңа Баулы авылының көнчыгыш почмагыннан 20 м ераклыкта Ык елгасының уңъяк ярында урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып, Исергәп – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,48 км төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 1,72 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба, Баулы елгасын кисеп үтеп, 440 м төньяк-көнбатышка таба, 280 м төньяк-көнчыгышка таба, 975 м төньяк-көнбатышка таба бораулау җайланмасына кадәр бара, аны көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 180 м төньяк-көнбатышка таба, 95 м көньяк-көнбатышка таба бораулау җайланмасына кадәр уза, аны көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 810 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 560 м көнбатышка таба, 110 м төньякка таба, 1,11 км көнбатышка таба Александровка, Исергәп һәм Кызылъяр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ютазы участок урманчылыгындагы 188 нче

урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза. ";

б) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Исергәп авыл җирлеге чиге "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып тондыру бассейннарының төньягы буйлап, сынык сызык ясап, көнчыгыш юнәлештә инеш белән кисешкән җиргә кадәр, аннары күмәк бакчаларның көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба Нефтьче-5 күмәк бакчасына кадәр уза, Нефтьче-5 күмәк бакчасының төньягы буйлап көньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң Бораулау эшләре идарәсе күмәк бакчасын әйләнеп үтә, аннары төзелеш материаллары заводы күмәк бакчасының төньягы буйлап җитештерү объектының уртасына кадәр, шуннан соң 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба электр подстанциясенә кадәр, аннары 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба скважинага кадәр, аннары сынык сызык буенча 1,96 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары 440 м төньяк-көнбатыш юнәлештә, шуннан соң 270 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,2 км төньяк-көнбатышка таба бара, 640 м көньяк-көнбатыш юнәлештә автомобиль юлына кадәр уза, аннары 650 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң көнбатышка таба Баулы елгасының төньягы буйлап "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге, Александровка һәм Исергәп авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "Баулы урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баулы участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш почмагында урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Исергәп авыл җирлеге чиге Александровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып көнбатыш юнәлештә "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ютазы участок урманчылыгындагы 188, 187, 186 нчы урман кварталларының көньягы буйлап, шуннан соң, "Баулы урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баулы участок урманчылыгындагы 36 нчы урман кварталын әйләнеп үтеп, 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

д) уникенче һәм унөченче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 6 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта ", Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кызылъяр авыл җирлеге чиге Исергәп авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып, Исергәп – Азнакай автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,48 км төньяк-көнбатышка таба күмәк бакчаларның көньяк-көнбатыш ягы буйлап, 1,72 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба, Баулы елгасын кисеп үтеп, 440 м төньяк-көнбатышка таба, 280 м төньяк-көнчыгышка таба, 975 м төньяк-көнбатышка таба бораулау җайланмасына кадәр бара, аның көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 180 м төньяк-көнбатышка таба, 95 м көньяк-көнбатышка таба бораулау җайланмасына кадәр уза, көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап әйләнеп үтә, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 810 м төньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 560 м көнбатышка таба, 110 м төньякка таба, 1,11 км көнбатышка таба Александровка, Исергәп һәм Кызылъяр авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында "Бөгелмә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ютазы участок урманчылыгындагы 188 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза. ";

в) җиденче һәм сигезенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 26-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Баулы муниципаль районының «Исергәп авыл җирлеге» һәм «Кызылъяр авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чиге участогы карта-схемасы




Шартлы билгеләр

торак пункт

җирлекләрнең чикләре

Исергәп авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Кызылъяр авыл җирлеге территориясе

Кызылъяр авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Исергәп авыл җирлеге территориясе